СОВЕТ МАМАДЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МАМАДЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ СОВЕТЫ

**Решение** **Карар**

№ 10-6 от «14» апреля 2026 г.

Мамадыш муниципаль районы Советының 2024 елның 1 ноябрендәге «Мамадыш муниципаль районының социаль-икътисадый үсеш фонды турында» 1-36 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Россия Федерациясенең «Коммерциягә карамаган оешмалар турында» 1996 елның 12 январендәге № 7-ФЗ Федераль закон, Мамадыш муниципаль районы Советының 2011 елның 15 апрелендәге «Мамадыш муниципаль районының социаль-икътисадый үсеш Фонды турында» 3-5 номерлы карары, Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районының социаль-икътисадый үсеш фонды Уставы, «Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә Мамадыш муниципаль районы Советы КАРАР КАБУЛ ИТТЕ:

1. Мамадыш муниципаль районы Советының 2024 елның 1 ноябрендәге «Мамадыш муниципаль районының социаль-икътисадый үсеш фонды турында»

1-36 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районының социаль-икътисадый үсеш фонды Уставына (алга таба- Устав) түбәндәге үзгәрешләрне һәм өстәмәләрне кертергә:

1.1. Фонд Уставының 2.1 пунктына түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«-гражданнарны Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә һәм ирекле формированиеләргә җәлеп итүгә ярдәм итү.».

2. Фонд Уставына үзгәрешләр кертелүгә бәйле рәвештә, фондның башкарма директоры Салахов Салих Гасыйм улына Россия Федераль салым хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча 18 нче районара инспекциясенә Фонд Уставына кертелгән үзгәрешләрне дәүләт теркәвенә алу өчен барлык кирәкле документларны тапшыруны йөкләргә.

000023

3. Әлеге карарны Мамадыш муниципаль районының http://mamadysh.tatarstan.ru рәсми сайтында, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Мамадыш муниципаль районы Башлыгы урынбасары, Мамадыш муниципаль районы Советы рәисе урынбасары Р.Р. Самигуллинга йөкләргә.

Мамадыш муниципаль район
Башлыгы В.И. Никитин